Республика Татарстан

Исполнительный комитет
Менделеевского
муниципального района

Татарстан Республикасы

Менделеевск муниципаль
районы
башкарма комитеты

ПОСТАНОВЛЕНИЕ
17.06.2025

Менделеевск
ш.

КАРАР
№ 399

2025 елның II яртыеллыгына торак урынынан файдаланган өчен түләү (найм өчен түләү) күләме турында

Россия Федерациясе Торак кодексының 156, 158 статьяларына, Россия Федерациясе Хөкүмәтенең «Күпфатирлы йортта гомуми мөлкәтне тоту кагыйдәләрен һәм күпфатирлы йортта гомуми мөлкәтне тоту һәм ремонтлау эшләрен тиешенчә булмаган сыйфатта һәм (яисә) билгеләнгән дәвамлылыктан артып киткән өзеклекләр белән башкарган очракта торак урынны карап тоту һәм ремонтлау өчен түләү күләмен үзгәртү кагыйдәләрен раслау турында» 2006 елның 13 сентябрендәге 491 номерлы карары, Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Торак һәм коммуналь хезмәтләр күрсәткәндә халык хокукларын һәм мәнфәгатьләрен яклау системасының нәтиҗәлелеген арттыру чаралары турында " 2010 елның 19 февралендәге 85 номерлы карары нигезендә, Татарстан Республикасы Менделеевск муниципаль районы Башкарма комитеты КАРАР БИРӘ:

1. 2025 елның 1 июленнән 2025 елның 31 декабренә кадәр социаль наем шартнамәләре һәм дәүләт һәм муниципаль торак фондының торак урыннарына наем шартнамәләре буенча торак урыннардан файдаланган өчен түләү күләмен (наем өчен түләү) 14,34 сум күләмендә расларга һәм гамәлгә кертергә.

2. Найм өчен түләү “Татарстан Республикасы Менделеевск муниципаль районының һәм Менделеевск шәһәренең социаль наем шартнамәләре һәм дәүләт яки муниципаль торак фондының торак урыннарын наем шартнамәләре буенча торак урыннарыннан файдаланган өчен түләү күләмен раслау турында” Татарстан Республикасы Менделеевск муниципаль районы Башкарма комитетының 2024 елның 28 июнендәге 404 номерлы карары нигезендә формулалар буенча исәпләнгән һәм коэффициентларны исәпкә алып, аена торак урынның гомуми мәйданының 1 кв. метрына исәпләнә

3. Найм өчен түләү дәүләт һәм муниципаль торак фондының торак урынын наймга бирүдән Татарстан Республикасы Менделеевск муниципаль районы бюджетының кереме булып тора (Россия Федерациясе Бюджет кодексының 41 ст.3 п.).

4. Торак урынны наймга алган өчен түләү Татарстан Республикасы Менделеевск муниципаль районы бюджетына Татарстан Республикасы буенча федераль казначылыкның түбәндәге реквизитлары буенча күчерелә (Менделеевск муниципаль районы мөлкәт һәм җир мөнәсәбәтләре палатасы) ш/с 04113000700 ИНН 1627005546 КПП 162701001 ЕКС 40102810445370000079 Казначейский счет 03100643000000011100 ОТДЕЛЕНИЕ–НБ РЕСПУБЛИКА ТАТАРСТАН БАНКА РОССИИ//УФК по Республике Татарстан г. Казань БИК ТОФК 019205400 ОКТМО: 92639000 КБК 803 1 11 09045 05 0000 120.

5. Әлеге карарны Татарстан Республикасы Менделеевск муниципаль районының рәсми сайтында урнаштырырга. mendeleevsk.tatarstan.ru һәм Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматыныд рәсми порталында бастырып чыгарырга pravo.tatarstan.ru.

6. Әлеге карар 2025 елның 1 июленнән барлыкка килгән хокук мөнәсәбәтләренә кагыла.

7. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны Башкарма комитет җитәкчесенең төзелеш һәм торак-коммуналь хуҗалык буенча беренче урынбасары А.Ф. Искаковка йөкләргә.

Җитәкче Р.Р. Искәндәров

КИЛЕШТЕРЕЛГӘН:

Башкарма комитетның юридик бүлеге башлыгы Е.С. Царева